**Рәис БЕЛЯЕВ,**
*1969-1984 елларда КПСС ның*
*Чаллы шәһәре комитеты беренче секретаре*

# БАТЫРЛЫК ҺӘМ МАТУРЛЫК ТАНТАНАСЫ

(чыгышыннан өзек)

КАМАЗ һәм шәһәр төзү чорында кичергән кыенлыкларыбыз һәм яулаган җиңүләребез турында сөйләгәндә, язучыларга, рәссамнарга, композиторларга, артистларга иң олы рәхмәт хисләребезне җиткерәсем килә. Алар беренче нигез ташы салынганнан алып, бүгенге көнгә кадәр безнең иң якын ярдәмчеләребез булдылар, үзләренең әсәрләре һәм ялкынлы сүзләре белән эшчеләрне һәм төзүчеләрне, инженер-техник работникларны һәм җитәкчеләрне яңадан-яңа җиңүләргә рухландырып тордылар. Мәскәү, Ленинград, Казан шәһәрләренең әдәбият-сәнгать осталары булышлыгы белән безнең үз шәһәребездә дә озакламый профессиональ иҗат оешмалары, йөзләгән үзешчән сәнгать коллективлары барлыкка килде.

Шулай бервакыт КПСС шәһәр комитеты киңәшмәсенә төзүчеләр һәм эшчеләр белән бергә без үзешчән сәнгать осталарын, клуб җитәкчеләрен, музыкантларны, яшь язучыларны да чакырдык. Кайбер хуҗалык җитәкчеләре башта моңа гаҗәпләнеп калганнар иде. Ә инде КАМАЗ төзергә килгән йөз меңләгән яшь буын вәкилен идея-эстетик, рухи тәрбияләү зарурлыгы турында зурдан кубып сөйли башлагач һәм әдәбият-сәнгать осталарының бу өлкәдә нинди эш башкара алулары турында басым ясап әйткәч, киңәшмә эше тагын да җанланыбрак китте.

Шәһәрдә яңа үзешчән театрлар, вокаль-инструменталь ансамбльләр, хореография коллективлары, халык уен кораллары оркестры барлыкка килде, үзешчән композиторлар, яшь рәссамнәр, музыкантлар, җырчылар, язучылар һәм шагыйрьләр үсеп чыкты. «Ләйсән» һәм «Орфей» әдәби берләшмәләренә йөрүче яшь язучыларның әсәрләре район һәм республика газет-журналларында гына басылып калмыйча, үзәк матбугатта да бик еш дөнья күрә башлады, бер-бер артлы аларның коллектив җыентыклары, соңрак үз китаплары чыкты. 1980 елның башында РСФСР Язучылар союзы идарәсе карары белән Чаллы язучылар оешмасы ачылгач, тәҗрибәле каләм осталары һәм яшь талантлар өчен зур әдәби проблемалар турында бергә-бергә фикер алышу, бер-берсенең әсәрләрен уртага салып сөйләшү, профессиональ осталыкларын арттыру, тормыш белән әдәбият арасындагы бәйләнешләрне тагын да ныграк ныгыту мөмкинлекләре күбәйде.

Хәзер Чаллы Язучылар оешмасында СССР Язучылар союзының 9 члены, 200 дән артык яшь һәм башлап язучы исәпләнә. Филология фәннәре докторы, тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин, язучылар Эдуард Касыймов, Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяров, Мәхмүт Газизов, Равил Вәлиев, Рахмай Хисмәтуллин һәм алар белән янәшә торып иҗат итүче Ямаш Игәнәй, Газиз Кашапов, Наил Лаисов, Хәниф Хөснуллин, Рафис Сәлимҗанов, Альберт Сафин кебек яшь талант ияләре КАМАЗ елъязмасына үзләренең лаеклы

өлешләрен керттеләр. Аларның күбесе хаклы рәвештә күкрәкләрендә «КАМАЗ төзелеше ударнигы» значогын йөртә. Шагыйрь һәм прозаик Равил Вәлиев оешмага җитәкче булып килде. Язучылар оешмасы көннән-көн ныгый бара, хәзер инде ул шәһәр күләмендә үткәрелгән бер генә зур чарадан да, бер генә олы вакыйгадан да читтә калмый. Язучылар һәм үзешчән сәнгать осталары кешеләрнең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аларга идея-эстетик тәрбия бирүнең никадәр кирәкле, зур һәм катлаулы эш икәнен аңлап, аны образлы телдә «КАМАЗның өченче чиратын төзү» дип атыйлар.

Моңа кадәр эшләгән эшләренә югары бәя биргән хәлдә, без язучылардан һәм культура фронты хезмәткәрләреннән әле КАМАЗ киңлегенә тиң әсәрләр, КАМАЗ төзүчеләре һәм эшчеләре хезмәтенә тәңгәл килерлек ялкынлану, илһамлану көтәбез, киләчәктә дә алар халыкның, партия һәм совет органнарының ышанычлы ярдәмчеләре булырлар дип уйлыйбыз.

*// Казан утлары. – 1982. – № 6. – Б. 4-10.*